КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 4 август

г.Казань

№ 757

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында» 2018 ел, 24 декабрь, 1214 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 10 июль, 563 нче; 2019 ел, 16 июль, 586 нчы; 2019 ел, 5 ноябрь, 1011 нче; 2019 ел, 27 декабрь, 1222 нче; 2020 ел, 10 июнь, 480 нче; 2020 ел, 31 август, 762 нче; 2020 ел, 16 декабрь, 1143 нче; 2021 ел, 29 октябрь, 1017 нче; 2022 ел, 24 гыйнвар, 44 нче, 2022 ел, 10 май, 426 нчы, 2022 ел, 15 июль, 677 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторлары) кертелмәгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлегенә (классификаторына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

16 бүлектә:

16.1 пунктта:

6 графада «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

7 графада «эш» сүзен «хезмәт күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга;

14 графаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«үткәрелгән экспертизалар саны, берәмлек»;

түбәндәге эчтәлекле 16.2 пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «16.2. | җинаять, граждан, арбитраж эшләре һәм административ хокук бозулар буенча суд экспертизалары (Россия Федерациясе законнары нигезендә чыгымнар федераль бюджет акчасы исәбеннән каплана (кертелә) торган очракларда), шулай ук алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүче заводларны план буенча тикшергәндә суд экспертизалары һәм эксперт тикшеренүләре производствосы | | | | хезмәт күрсәтү | дәүләт хезмәте күрсәтү түләүсез | 71.2; 71.20.1; 84.23 | 01.01.2022 | 31.12.2099 | Татарстан Республикасы | бюджет, автоном | дәүләт хакимиятенең башкарма органы | үткәрелгән экспертизалар саны, берәмлек | | юк | юк | 1) «Россия Федерациясендә дәүләт суд-эксперт эшчәнлеге турында» 2001 елның 31 маендагы 73-ФЗ номерлы Федераль закон (11 статья); 2) Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының «Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы каршындагы Россия федераль суд экспертизасы федераль бюджет учреждениесе Уставын раслау турында» 2014 елның 31 мартындагы 49 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы каршындагы Россия федераль суд экспертизасы үзәге федераль бюджет учреждениесе уставы (2.3 пункт); 3) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика бәйсез экспертиза үзәге һәм кулланучылар базарын мониторинглау» дәүләт бюджет учреждениесе турында» 2005 ел, 29 декабрь, 649 нчы карары. |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга Татарстан Республикасы аерым дәүләт учреждениеләренең норматив чыгымнарын раслау турында» 2021 ел, 30 сентябрь, 931 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 25 ноябрь, 1124 нче, 2021 ел, 24 декабрь, 1277 нче, 2021 ел, 24 декабрь, 1284 нче, 2022 ел, 15 гыйнвар, 19 нчы, 2022 ел,

29 март, 284 нче, 2022 ел, 05 май, 420 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан башкарыла торган дәүләт эшләренә норматив чыгымнарның 6 бүлеген үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карар белән расланган 2022 елга Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләренә норматив чыгымнар һәм аларның күләмнәренә түбәндәге эчтәлекле 5 бүлек өстәргә:

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| «5. | Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе учреждениеләре | | | | |
| 5.1. | «Бәйсез экспертиза һәм кулланучылар базары мониторингы республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе | җинаять, граждан, арбитраж эшләре һәм административ хокук бозулар буенча суд экспертизалары (Россия Федерациясе законнары нигезендә чыгымнар федераль бюджет исәбеннән каплана (кертелә) торган очракларда), шулай ук җинаять турындагы хәбәрне тикшергәндә суд экспертизалары һәм эксперт тикшеренүләре производствосы | 4 916,0 | 1 503,0 | үткәрелгән экспертизалар саны, берәмлек |
| | | җинаять, граждан, арбитраж эшләре һәм административ хокук бозулар буенча суд экспертизалары (Россия Федерациясе законнары нигезендә чыгымнар федераль бюджет акчасы исәбеннән каплана (кертелә) торган очракларда), шулай ук алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүче заводларны план буенча тикшергәндә суд экспертизалары һәм эксперт тикшеренүләре производствосы | 2 616,0 | 5,0 | үткәрелгән экспертизалар саны, берәмлек». |

3. Бу карарның гамәле 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин